РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

18 ноябрь 2024 ел Буа шәһәре № 1-69

2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план
чорына Татарстан Республикасы Буа
муниципаль районы бюджеты
проекты турында

Буа муниципаль районының финанс-бюджет палатасы рәисе А. Р. Әюпов докладын тыңлап, 2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы бюджеты проектын карап, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы

**КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:**

1. 2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы бюджеты проектын беренче укылышта кабул итәргә (әлеге карарга кушымта итеп бирелә).

2. 2025 елга һәм 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы бюджеты проекты буенча ачык тыңлауларны 2024 елның 4 декабренә Буа муниципаль районы Башкарма комитетының утырышлар залында 10.00 сәгатькә билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Буа муниципаль районының Интернет мәгълүмати коммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (https://buinsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

Буа муниципаль районы башлыгы,
Совет рәисе Р.Р. Камартдинов

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы
Советының 2024 елның 18 ноябрендәге
1-6 номерлы карарына кушымта

2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы бюджеты проекты

1 статья

1. 2025 елга Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы бюджетының төп характеристикаларын түбәндәге төп характеристикалар белән расларга:

1) Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләме 1 871 312,56 мең сум күләмендә;

2) Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен 1 871 312,56 мең сум итеп.

3) Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы бюджеты кытлыгын 0,00 мең сум итеп.

2. 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы бюджетының төп характеристикаларын расларга:

1) Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләме - 2026 елга 1 976 278,80 мең сум, 2027 елга 2 105 565,05 мең сум күләмендә;

2) Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы бюджеты чыгымнарының гомуми күләме:

- 2026 елга 1 976 278,80 мең сум күләмендә, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар 21 500,00 мең сум күләмендә;

- 2027 елга 2 105 565,05 мең сум күләмендә, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар 43 800,00 мең сум күләмендә;

3) Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы бюджеты кытлыгын 2026 елга 0 сум һәм 2027 елга 0 сум итеп.

3.2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә расларга.

2статья

1. 2026 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы муниципаль эчке бурычының нуль әһәмиятле югары чиген, шул исәптән Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы муниципаль гарантияләре буенча Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы муниципаль эчке бурычының югары чиген Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы муниципаль гарантияләре буенча Россия Федерациясе валютасында нуль әһәмиятле итеп расларга.

2. 2027 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Эчке муниципаль бурычының нуль әһәмиятле югары чиген, шул исәптән Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы муниципаль гарантияләре буенча Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы муниципаль эчке бурычының югары чиген Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы муниципаль гарантияләре буенча Россия Федерациясе валютасында нуль әһәмиятле итеп расларга.

3. 2028 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Эчке муниципаль бурычының нуль әһәмиятле югары чиген, шул исәптән Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы муниципаль гарантияләре буенча Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы муниципаль эчке бурычының югары чиген Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы муниципаль гарантияләре буенча Россия Федерациясе валютасында нуль әһәмиятле итеп расларга.

3статья

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы бюджетында 2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы бюджеты керемнәренең фаразлана торган күләмнәрен әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә исәпкә алырга.

4статья

Әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигатьтән файдалану өлкәсендәге административ хокук бозулар өчен административ штрафлардан, әйләнә-тирә мохиткә, шул исәптән су объектларына, мәҗбүри таләпләрне бозу аркасында, әйләнә-тирә мохиткә, шул исәптән су объектларына китерелгән зыянны ирекле каплаганда түләнә торган зыянны каплау турындагы дәгъвалар буенча түләүләрдән, мәҗбүри таләпләрне бозу аркасында әйләнә-тирә мохиткә җыелган зыянны ачыклау һәм бәяләү, әйләнә-тирә мохиткә җыелган зыянны бетерү эшләрен оештыру, әйләнә-тирәлеккә хуҗалык эшчәнлегенең һәм башка эшчәнлекнең тискәре йогынтысын булдырмау һәм (яки) киметү, табигый тирәлекне саклау һәм торгызу, табигый ресурслардан рациональ файдалану һәм яңадан торгызу, экологик куркынычсызлыкны тәэмин итү буенча башка чараларга, Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә вәкаләтле башкарма хакимият органы тарафыннан раслана торган табигать саклау чаралары планы нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләтле башкарма хакимиятнең федераль органы белән килештереп, әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясаган өчен түләүдән җирле бюджетка күчерелгән салым булмаган керемнәр дип билгеләргә.

5 статья

1.2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы бюджеты чыгымнарының ведомство структурасын әлеге карарга 3 нче кушымта нигезендә расларга.

2. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы бюджетының бюджет ассигнованиеләрен 2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына бюджетлар чыгымнары классификациясенең бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары (Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы муниципаль программалары һәм эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләре), чыгымнар төрләре төркемнәре буенча бүлүне әлеге карарга 4 нче кушымта нигезендә расларга.

3. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы бюджетының бюджет ассигнованиеләрен 2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына бюджетлар чыгымнары классификациясенең максатчан статьялары (Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы муниципаль программалары һәм эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләре), чыгымнар төрләре төркемнәре, бүлекләре, бүлекчәләре буенча бүлүне әлеге карарга 5 нче кушымта нигезендә расларга.

4.Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы бюджетының гавами норматив йөкләмәләрне үтәүгә җибәрелә торган бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләмен 2025 елга 37 641,50 мең сум, 2026 елга 38 413,50 мең сум һәм 2027 елга 39 445,70 мең сум итеп расларга.

6 статья

1. Төзелгән килешүләр нигезендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы җирлекләре бюджетларыннан алына торган башка бюджетара трансфертларны Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы бюджетында исәпкә алырга:

-2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына күпфатирлы йортларны капиталь ремонтлау чараларын тәэмин итүгә әлеге карарга 6 нчы кушымта нигезендә ел саен

3970,0 мең сум күләмендә;

-ял итүне оештыру һәм җирлекләрне мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру чараларын тәэмин итүгә 2025 елга 18 726,70 мең сум, 2026 елга 13 083,60 мең сум, 2027 елга 14 049,10 сум күләмендә әлеге карарга 7 нче кушымта нигезендә.

7статья

Җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр күләмен расларга:

2025 елга 88 528,30 мең сум күләмендә;

2026 елга 87 060,67 мең сум күләмендә;

2027 елга 88 663,50 мең сум күләмендә

әлеге карарның 8 нче кушымтасы нигезендә бүлеп.

8статья

Татарстан Республикасы бюджетыннан алына торган бюджетара трансфертларны Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы бюджетында исәпкә алырга:

2025 елда 1 155 090,56 мең сум күләмендә;

2026 елда 1 216 163,50 мең сум күләмендә;

2027 елда 1 299 614,15 мең сум күләмендә

әлеге карарга 9 нчы кушымта нигезендә бүлеп.

9статья

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы юллар фондының бюджет ассигнованиеләре күләмен расларга:

2025 елга 34 255,30 мең сум күләмендә;

2026 елга 35 310,50 мең сум күләмендә;

2027 елга 36 722,90 мең сум күләмендә

һәм аларны тиешенчә 2025, 2026 һәм 2027 елларда Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының гомуми файдаланудагы юлларында юл эшләре программасы чараларын гамәлгә ашыруга җибәрергә.

10 статья

Юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга һәм физик затларга – товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) җитештерүчеләргә субсидияләр Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитеты билгеләгән тәртиптә бирелә.

11статья

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының җирле үзидарә органнары, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының җирле үзидарә органнарына, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының муниципаль казна учреждениеләренә яңа функцияләр яисә вәкаләтләр бирүгә бәйле рәвештә мондый карарлар кабул итү очракларыннан тыш, муниципаль хезмәткәрләрнең һәм бюджет өлкәсендәге башка оешмаларның хезмәткәрләренең санын арттыруга китерә торган карарларны 2025 елда кабул итәргә хокуксыз.

2. Җирлекләрнең җирле үзидарә органнарына 2025 елда муниципаль хезмәткәрләр санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итмәскә киңәш итәргә.

12статья

2025 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы бюджеты акчаларының калдыклары 2024 елда әлеге муниципаль контрактлар шартлары нигезендә түләнергә тиешле товарлар китерүгә, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы исеменнән төзелгән муниципаль контрактларга түләүгә файдаланылмаган бюджет ассигнованиеләре калдыгы

суммасыннан артмаган күләмдә, 2025 елда Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы башкарма комитеты тиешле карар кабул иткән очракта күрсәтелгән максатларга тиешле бюджет ассигнованиеләрен арттыруга юнәлдерелә.

13статья

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Буа районы Казначылык Департаментының территориаль бүлеге төзелгән килешүләр нигезендә Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы бюджетын үтәү буенча аерым функцияләрне башкара.

14статья

Әлеге карарны Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтына, ТР хокукый мәгълүматның рәсми порталына http://pravo.tatarstat.ru. урнаштырырга.

15статья

Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Буа муниципаль районы башлыгы,
Совет рәисе Р.Р.Камартдинов